| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабря 2025 г. с.Шалты № 13

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының «Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 15.02.2022 № 32 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 03.10.2025 ел, № 66-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 15.02.2022, № 32 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (31.03.2023 № 59, 14.07.2023 № 71, 16.08.2023 № 73, 25.03.2024 № 89, 23.05.2024 № 97, 21.02.2025 № 114 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6.1. пунтны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:

авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Баулы муниципаль районы
Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Фаткуллин З.Х.